**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2014 елның 15 мартындагы ПУ-275 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-196 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-236 номерлы, 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-329 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-89 номерлы, 2020 елның 6 мартындагы ПУ-158 номерлы, 2021 елның 15 апрелендәге ПУ-287 номерлы, 2022 елның 23 апрелендәге ПУ-296 номерлы, 2022 елның 13 октябрендәге ПУ-739 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 22 апрелендәге 251 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан М.Х. Сәлаховны чыгарырга;

б) Комиссия составына Миңнеханов Рифкать Нургали улын – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президентын кертергә (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 16 март
№ 202